Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге
Ирек-Тан авылы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» ноябрь 2023 ел № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Ирек-Тан авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Ирек-Тан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Борды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Ирек Тан авылы су белән тәэмин итү хәл итүгә.

«Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 22 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча җыелган акчалар хисабына эш төрен үзгәртергә ризамы:

- « Ирек Тан авылы скважина бораулауны -29250 сум» – « Ирек Тан авылы су белән тәэмин итүгә -29250 сум» хәл итүгә.

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Ирек-Тан авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Ирек-Тан авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина